**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная, д.3,
г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

2024 елның 29 октябре 16номер

**КАРАР**

**16:24:170123:132 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьялары, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, Территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең 2024 елның 25 октябрендәге 9656/ исх номерлы мөрәҗәгате нигезендә, Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәре Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Лаеш шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Кызыл Армия ур., 30а йорт адресы буенча урнашкан 16:24:170123:132 кадастр номерлы, 150 кв. м. мәйданлы «Кибетләр» индивидуаль торак зонасында (Ж1) җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карары проектын карау буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү чорын – кызыксынучы затларга аларны үткәрү турында хәбәр иткән вакыттан алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә.

3. Эш комиссиясенә 16:24:170123:132 номерлы җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы карары проектын карау буенча гавами тыңлауларны оештыруда һәм уздыруда әзерлек үткәрергә.

1.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

1.2. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән соң ике эш көне дәвамында Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә, карар кабул итү өчен документлар комплекты кушымтасы белән, хәбәр итәргә кирәк.

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- https://laishevo.tatarstan.ru/publichnoe-obsuzhdenie-5676969.htm веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче В.А. Арефьев